Azatlıq Radiosı

СУГЫШ

# Азатлык хисабы: Татарстаннан сугышта кимендә 10 мең хәрби һәлак булган

8 минут элек




Архив фотосы

**Татарстан һәм Башкортстаннан сугышта һәлак булган кимендә 20 796 хәрбинең исеме билгеле.**

Русия Украинага каршы алып барган сугышта Татарстаннан кимендә 10 мең хәрби һәлак булган. Бу санны Азатлык Радиосының "Сугышта үлүчеләр" хисабы күрсәтә. Исемлекне без сугыш башыннан бирле алып барабыз.

14 сентябрьгә исемлектә Татарстаннан **10 096** исем бар. Хисапка үлемнәре расланган кешеләрнең исемнәре, алар турында таба алган мәгълүмат кертелә. Бу журналистларыбыз таба алган исемнәр генә, хакимият тарафыннан рәсми югалту саннары аталмагач, бу эшне медиа һәм бәйсез күзәтүчеләр башкарырга мәҗбүр.

Сугышта һәлак булган хәрбиләр исемлеген Азатлык Радиосы ачык чыганаклардан: рәсми хәбәрләрдән, социаль челтәрләрдән, некрологлардан, башка хәбәрләрдән туплый. Хакимият сугышта үлүчеләр санын әйтми. Чын саннар күпкә зуррак булырга мөмкин.


Күрше Башкортстанда да үлгән хәрбиләр саны май ахырында 10 меңнән арткан иде. Бүгенгә республикадан без **10 700** һәлак булган хәрби турында мәгълүмат таптык. Ике республикада бергә кимендә **20 796** кеше һәлак булган.

Бер ел элек, 2025 елның 10 сентябрендә безнең исемлектә Татарстаннан һәлак булган **6012** хәрбинең исеме бар иде. Ягъни соңгы елда гына исемлеккә 4 мең хәрби исеме өстәлде. Сүз соңгы елда гына үлгән кешеләр турында бармый, исемлеккә 2025, 2024 елда һәлак булучылар да өстәлеп килә. Әмма соңгы елда аеруча күп кешенең үлеме дә күренә.

## Һәлак булучылар географиясе

Татарстанда иң күп кешесен югалткан шәһәр-районнар:

- **Казан** – кимендә **1758** кеше.
- **Чаллы** – кимендә **1102** кеше.
- **Түбән Кама районы** – кимендә **682** кеше.
- **Әлмәт районы** – кимендә **477** кеше.
- **Яшел Үзән районы** – кимендә **443** кеше.
- **Бөгелмә районы** – кимендә **367** кеше.




Татарстаннан иң зур югалтулар эре шәһәрләргә туры килә: Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән.

Иң аз үлем хәбәрләре – Әтнә (35), Теләче (53), Саба (72) районнарыннан. Бу районнарда халык саны болай да аз, уртача 12-14 мең кеше.

## Уртача яшь

Сугышта үлүчеләрнең яшенә килгәндә, төп үлемнәр элеккечә 35-44 яшь төркеменә туры килә:

- 35-44 яшь: кимендә **3722** кеше,
- 45+ яшь: кимендә **3084** кеше.
- 25-34 яшь: кимендә **2323** кеше,
- 18-24 яшь: кимендә **721** кеше,

Татарстаннан сугышка китеп һәлак булучыларның уртача яше — **39,38** яшьне тәшкил итә.

## Мобилизация: кимендә 1 мең һәлак булучы

Бу арада чыккан тагын бер мөһим хәбәр 2022 елның сентябрендә башланган мобилизациягә карый. Азатлык Радиосы үлгән хәрбиләрнең статусын барларга

тырышса да, бу статистика бездә тулы түгел, шуңа әлегә аны тулы рәвештә аналитика өчен кулланып булмый.

Әмма Русия буйлап һәлак булучылар исемлеген алып барган "Медиазона"да бу хакта тулырак мәгълүмат бар. Соңгы яңартуда күренгәнчә, Украинага каршы баскын сугышта Татарстаннан үлгән мобилизацияләнгәннәрнең саны 1 меңнән арткан. Хәзергә журналистлар кимендә **1033** кеше турында мәгълүмат таба алган.

Күрше Башкортстанда да мобилизациягә эләгеп, сугышта һәлак булучы кешеләрнең саны бер меңнән арткан. Журналистлар әлегә мондый **1061** очракны теркәгән. Өченче урында Бурятия республикасы бара: анды мондый **800** очрак ачыкланган.

Барлыгы Русиядән сугышта кимендә **20 350** мобилизацияләнүче үлеме теркәлгән.

Рәсмиләр һәр төбәкләрдән сугышка күпме кеше мобилизацияләнгәнен дә, күпме кешенең анда һәлак булуын да әйтми. Соңгы елларда чыккан некрологларда да мәрхүмнең сугышка нинди статуста киткәнен телгә алмаска тырышалар.



**БУ ТЕМАГА:**

Медиазона: Татарстаннан сугышка мобилизацияләнгәннәрнең кимендә 1 меңе һәлак булган

**🛑 Русиядә Азатлык сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
**🌐 Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

This item is part of

татарстан | башкортстан | сугыш

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар саклanган